Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №V-2**

Балык Бистәсе штп. 2020 елның 03 декабре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

“Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында”гы Федераль законга һәм “Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында” Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында”гы Федераль законның 1 һәм 2 маддәләренә үзгәрешләр кертү турында” 2020 елның 8 июнендәге 169-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2018 елның 4 сентябрендәге “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы милкендә булган, өченче затларның хокукларыннан (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан гайре) азат булган һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын хасил итүче оешмаларга бирү өчен аталган мөлкәт исемлеген формалаштыру, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару (игълан итү) тәртибен раслау турында” гы XXXIII-8 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) карарның аталышында, преамбуласы һәм 1 пунктында “кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын хасил итүче” сүзләреннән соң “, махсус салым режимын кулланучы физик затларга” сүзләрен өстәргә;

2) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2018 елның 4 сентябрендәге XXXIII-8 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы милкендә булган, өченче затларның хокукларыннан (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан гайре) азат булган һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын хасил итүче оешмаларга бирү өчен аталган мөлкәт исемлеген формалаштыру, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару (игълан итү) Тәртибендә

“кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын хасил итүче сүзләреннән соң “,махсус салым режимын кулланучы физик затларга” сүзләрен өстәргә;

аталыштагы “кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын хасил итүче сүзләреннән соң “,махсус салым режимын кулланучы физик затларга” сүзләрен өстәргә;

1 пунктта “кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын хасил итүче” сүзләреннән соң “индивидуаль эшкуар булмаган һәм ”Һөнәри керемгә салым” махсус салым режимын кулланучы физик затларга (алга таба – махсус салым режимын кулланучы физик затлар) сүзләрен өстәргә.”;

3 пунктта “кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын хасил итүче, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль учреждениеләренең һәм муниципаль унитар предприятиеләренең, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларының.” сүзләрен “кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын хасил итүче, махсус салым режимын кулланучы физик затларның, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль учреждениеләренең һәм муниципаль унитар предприятиеләренең, кече һәм урта эшкуарлык субъектларының, шулай ук махсус салым режимын кулланучы физик затларның.” сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2018 елның 4 сентябрендәге “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы милкендә булган өченче затлар хокукларыннан (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан гайре) азат булган муниципаль мөлкәт исемлегенә кертелгән һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын хасил итүче оешмаларга бирү өчен аталган муниципаль мөлкәтне арендага бирү Тәртибен һәм шартларын раслау турында”гы XXXIII-9 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) карарның аталышында, преамбуласы һәм 1 пунктында “кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын хасил итүче” сүзләреннән соң “, махсус салым режимын кулланучы физик затларга” сүзләрен өстәргә;

2) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2018 елның 4 сентябрендәге XXXIII-8 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы милкендә булган өченче затлар хокукларыннан (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан гайре) азат булган муниципаль мөлкәт исемлегенә кертелгән һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын хасил итүче оешмаларга бирү өчен аталган муниципаль мөлкәтне арендага бирү Тәртибе һәм шартларында

аталыштагы “кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын хасил итүче” сүзләреннән соң “,махсус салым режимын кулланучы физик затларга” сүзләрен өстәргә;

1.1. пунктында “кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын хасил итүче” сүзләреннән соң “индивидуаль эшкуар булмаган һәм ”Һөнәри керемгә салым” махсус салым режимын кулланучы физик затларга

(алга таба – махсус салым режимын кулланучы физик затлар)” сүзләрен өстәргә.;

1.5 пунктында “кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын хасил итүче” сүзләреннән соң “, махсус салым режимын кулланучы физик затларга” сүзләрен өстәргә;

2.5. пунктында “кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын хасил итүче” сүзләреннән соң “, махсус салым режимын кулланучы физик затларга” сүзләрен өстәргә;

3.3. пунктында “Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына,” сүзләреннән соң “, махсус салым режимын кулланучы физик затларга” сүзләрен өстәргә;

3.4. пунктында “кече һәм урта эшкуарлык субъектларына бирелгән,” сүзләреннән соң “һәм махсус салым режимын кулланучы физик затларга” сүзләрен өстәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы

И.Р. Таҗетдинов